МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.05.2020 Казан ш. № 21-75-92

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турындагы эшләрне, процессуаль документларның якынча рәвешләрен карауга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау хакында» 2015 елның 05 февралендәге 21-75-6 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләр, процессуаль документларның якынча рәвешләрен карарга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау хакында» 2015 елның 05 февралендәге 21-75-6 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2015 елның 25 декабрендәге 21-75-83 номерлы, 2017 елның 19 гыйнварындагы 21-75-12 номерлы, 2017 елның 18 октябрендәге 21-75-187 номерлы, 2019 елның 05 апрелендәге 21-75-59 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1.2 пунктчасының беренче абзацында:

«15.11,» саннарын төшереп калдырырга;

«15.15.16,» саннарыннан соң «15.41,» саннарын өстәргә;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ хокук бозулар турындагы эшләр карала дип билгеләргә:

3.1. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.29.3 статьясында, 7.32 статьясындагы 8 - 10 өлешләрендә, 7.32, 15.1, 15.14 - 15.15.16, 15.41 статьяларында, 19.5 статьясындагы 20 өлешендә һәм 19.7.2 статьясындагы 1 өлешендә каралган хокук бозулар составлары буенча:

- Татарстан Республикасы финанслар министры;

- министрның беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры.

3.2. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.29.3 статьясындагы 2 - 4 өлешләрендә, 15.15 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләрендә, 15.1 статьясындагы 1, 3 һәм 4 өлешләрендә, 15.15.5-1 статьясындагы 1 - 6 өлешләрендә, 15.15.7, 15.15.11, 15.15.14, 15.15.15 статьяларында каралган хокук бозулар составлары буенча - Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының контроль-ревизия бүлекчәләре эшчәнлеген координацияләүче казначылык департаменты директоры урынбасары.».

Министр Р.Р. Гайзатуллин